**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

31.03.2022 235-п

Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр кишәрлеге буенча аерым җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләмен билгеләү турында

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2021 елның 30 мартындагы 214 номерлы боерыгы белән расланган Җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләүләрнең конкрет күләмнәрен билгеләү тәртибе, «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы турындагы нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән тәртиптә лицензия бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларының һәр кишәрлеге буенча җир асты байлыкларыннан файдаланган өчен даими түләү ставкасының конкрет күләме «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 43 статьясында билгеләнгән даими түләүләрнең максималь ставкалары дәрәҗәсендә билгеләнә.
2. Җир асты байлыкларыннан файдалануны җайга салу бүлегенә әлеге боерыкны Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җиткерергә.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары И.И.Гойбәдуллинга йөкләргә.

Министр А.В. Шадриков